МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 гыйнвар 2017ел. № 11 03

Кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 53 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2015 елның 27 маендагы М 166 нчы карары белән расланган кешеләр күпләп җыела торган урыннарны тикшерү буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) составтан чыгарырга: М.Р. Фирстованы, Л.Л. Репинаны;

2) составка кертергә:

- Сабаев Олег Вильевичны – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесен (килешенү буенча);

- Нуриев Руслан Рәфкать улын – «ТР буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалының Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлегенең баш белгечен (килешенү буенча);

- Солтанова Рәисә Кәүсар кызын – Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгын;

- Кашихин Евгений Викторовичны – ТР буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы ДУ күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эшләре бүлеге башлыгын (килешенү буенча);

3) Р.Ә. Абдуллинның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе»;

4) В.Х. Харисовның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев